МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.10.2017 Казан шәһәре № под-1572/17

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре турында» 2017 елның 19 апрелендәге под-678/17 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре турында Положениегә үзгәрешләр кертү турында

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре турында» 2017 елның 19 апрелендәге под-678/17 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Ведомство бүләкләре белән бүләкләнәләр:

мәгариф өлкәсе оешмалары, фәнни, фәнни-техник эшчәнлек, тәрбия, балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек хезмәткәрләре, белем бирү оешмалары укучыларына социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль яклау, яшьләр сәясәте, башка өлкәләр хезмәткәрләре-күренекле казанышлары (казанышлары) һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен (хезмәте));

белем бирү оешмалары укучылары (тәрбияләнүчеләр, студентлар, аспирантлар) - укудагы уңышлары өчен.»;

1.4 пунктында:

«тәрбиячеләре һәм башка хезмәткәрләре бүләкләнә» сүзләрен төшереп калдырырга

«тәрбиячеләре һәм башка хезмәткәрләре түбәндәге казанышлары өчен бүләкләнә» сүзләренә алмаштырырга

1.5 пунктының сигезенче абзацында түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә::

«Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен укучыларга карата таләпләр Министрлык тарафыннан билгеләнә»;

2.3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2.6 пунктының алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«2.13. Тәкъдим ителгән документларны әлеге Положение белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү буенча тикшерү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре буенча комиссиянең (алга таба - Комиссия) җаваплы секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Комиссия, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры боерыгы белән, билгеләнгән тәртиптә тәкъдим ителгән бүләкләү турындагы документларны алдан карау өчен төзелә. Комиссиянең эше тәртибе һәм аның составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры боерыклары белән раслана.

Әлеге Положение тарафыннан билгеләнгән таләпләрне бозып тәкъдим ителгән бүләкләү турындагы документлар, ачыкланган җитешсезлекләрне күрсәтеп, 7 көнлек срокта кире кайтарылырга тиеш. Җитешсезлекләрне бетергәннән соң, бүләкләү турындагы документлар, кабат тәкъдим ителергә мөмкин.

Комиссия тәкъдиме нигезендә Министрлык 30 көн эчендә кандидатны ведомство бүләге белән бүләкләү турында яки бүләкләүдән баш тарту турында Карар кабул итә.».

3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

3.3. Ведомство бүләкләре Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры яисә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасарлары тарафыннан тапшырылмаган очракта, бүләкләү турында боерык

чыгарганнан соң 6 айлан да соңга калмыйча, хезмәткәрне бүләкләүгә тәкъдим иткән оешма (органнар) вәкилләренә бирелә.

Бүләкләнүче хезмәт итә торган оешма, Татарстан Республикасы муниципаль районы территориясендә урнашкан әлеге оешма, мәгариф бүлегенә (идарәсе) 30 көн эчендә ведомство бүләкләрен тапшыру турында хәбәр итә. Муниципаль район мәгариф бүлеге (идарә) министрлыкка, оешмадан мәгълүмат алганнан, соң 7 көн эчендә, ведомство бүләкләрен тапшыру турында хәбәр итә.»;

IV бхлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

IV. Ведомство бүләкләре тасвирламасы

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе сары металлның җиңел сплавыннан әзерләнә, 26 мм диаметрлы түгәрәк дискка ия.

Күкрәк билгесенең алгы ягында ачык китап, аның янында лавр тәлгәше рельеф сурәте, түгәрәктә сулдан һәм уң яктан «Мәгарифтәге казанышлары өчен» һәм «За заслуги в образовании»дигән язулар урнаштырылган.

Ушка һәм боҗра ярдәмендә Медаль Татарстан Республикасы Дәүләт флагы рәвешендә эшләнгән 26 х 16 мм зурлыгында турыпочмаклы колодка белән тоташтырыла.

Икенче якта билгене кием-салымга беркетү өчен булавка бар.

Күкрәк билгесе күкрәкнең уң ягында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән түбәнрәк йөртелә.

Таныклыкның размеры: киңлеге - 222 мм., биеклеге 148 мм. Уртага бөкләнгән хәлдә - 109х148 мм; эчке киселешнең размеры: 99х142мм (уң һәм сул өлештә 2 данә).

Таныклыкның тышы, тыгызлыгы 145 гр/кв. дан ким һәм 150 гр/кв. дан артмаган, караңгы-яшел төстәге тышлык материалыннан әзерләнә.

Таныклыкның алгы өлешенең бизәлеше: кайнар алым белән металланган «алтын» фольга белән төшерелгән бизәк. Түгәрәкләнгән почмаклар, тоташкан урында кисемтә белән.

Таныклыкның эчке өлешен бизәкләү Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының рәсми һәм эшлекле стиль элементларын төзү һәм куллану визуаль стандартлары паспорты турында» 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-880 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы рәсми һәм эшлекле стиль элементларын төзүнең һәм куллануның визуаль стандартлары паспорты нигезендә төгәл гамма нигезендә уздырыла (алга таба - Татарстан Республикасы рәсми һәм эшлекле стиль элементларын төзүнең һәм куллануның визуаль стандартлары паспорты).

Мактау грамоталары тыгызлыгы 145 г/кв.м дан ким, 175 г/кв.м дан: артык булмаган кәгазьдән эшләнә. Мактау грамотасының размерлары: киңлеге - 420 мм, биеклеге - 297 мм., икегә бөкләнгән килеш - 210х297 мм.

Мактау грамоталарын бизәкләү Татарстан Республикасының рәсми һәм эшлекле стиленең визуаль стандартлары паспортына туры килгән төгәл гаммада башкарыла.

Рәхмәт хаты тыгызлыгы 145 г/кв.м дан ким, 175 г/кв.м дан: артык булмаган кәгазьдән эшләнә. Размеры: киңлеге - 210 мм, биеклеге - 297 мм.

Рәхмәт хатларын бизәкләү Татарстан Республикасының рәсми һәм эшлекле стиленең визуаль стандартлары паспортына туры килгән төгәл төсләр гаммасында башкарыла.

Министрлыкның Рәхмәте (благодарность) тыгызлыгы 145 г/кв.м дан ким, 175 г/кв.м дан артык булмаган кәгазьдән эшләнә. Министрлыкның Рәхмәтен бизәкләү Татарстан Республикасының рәсми һәм эшлекле стиленең визуаль стандартлары паспортына туры килгән төгәл төсләрдә башкарыла.

2. Кадрлар сәясәте бүлегенә (Н.Б Алексеева) боерык кабул ителгәннән соң, 3 көнлек срокта, аны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Премьер-
министры урынбасары – министр Э.Н.Фаттахов